Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы

Карар

28 нче апрель 2022нче ел №9

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырырга бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырырга бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының «Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 1нче апрелендагы 17 номерлы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 01нче апрелендагы 17 номерлы карары белән расланган Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 28 маендагы 26 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: И.М.Нәбиев

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2022 елның «28» апреле 07 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырырга бирү тәртибе турында Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның (алга таба – муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар), аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Кукмара муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба - рәсми сайт) урнаштырыла, ә бу белешмәләр рәсми сайтта булмаган очракта – аларның соратулары буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында түбәндәге мәгълүмат рәсми сайтта урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә:

а) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затка, аның иренә (хатынына) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында яисә аларда файдалануда булган, мондый объектларның һәркайсының төрен, мәйданын һәм урнашу илен күрсәтеп, күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге;

б) муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче (биләгән) затның, аның иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында булган транспорт чаралары исемлеге, төрен һәм маркасын күрсәтеп;

в) муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче (биләгән) затның, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешен), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр кылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә хезмәткәрнең (эшләүченең) һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә.

3. рәсми сайтта урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә торган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларда түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, күрсәтелгән затларга милек хокукындагы мөлкәт турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка белешмәләр (әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш);

б) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның хатынының (иренең), балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының шәхси мәгълүматлары;

в) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның, аның хатыны (ире), балаларының һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка шәхси коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр;

г) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затка, аның иренә (хатынына), балаларына, гаиләнең башка әгъзаларына караган милек хокукында яки алардан файдалануда булган күчемсез милек объектларының урнашуын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

д) дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүмат.

4. Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүченең аларны биләү керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыруга китерә торган вазыйфаларны биләүнең бөтен чорына белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр рәсми сайтта була, ел саен аларны бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көне эчендә яңартыла.

5. Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне рәсми сайтта урнаштыру Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә кадрлар эше өчен җаваплы затлар (алга таба – кадрлар эше өчен җаваплы затлар) тарафыннан тәэмин ителә.

6. Кадрлар эше өчен җаваплы затлар:

а) массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау кергән көннән соң өч эш көне эчендә аңа карата запрос кергән муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торучы затка бу турыда хәбәр итәләр;

б) массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган көннән алып җиде эш көне эчендә, әгәр соралган белешмәләр рәсми сайтта юк икән, аңа әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүне тәэмин итәләр.

7. Кадрлар эше өчен җаваплы затлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә, әлеге тәртипне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булган белешмәләрне игълан иткән өчен җаваплы.